МИНИСТЕРСТВО
СЕЛЬСКОГО ХОЗЯЙСТВА
И ПРОДОВОЛЬСТВИЯ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫ
ҺӘМ АЗЫК-ТӨЛЕК
МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

31.03.2017 г.Казань № 70/2-пр

"2017 – 2020 елларга Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперациясен үстерү" ведомство максатчан программасын раслау турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең "Агросәнәгать комплексын үстерүнең региональ программаларының максат күрсәткечләренә ирешүгә ярдәм итү очен Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына федераль бюджеттан субсидияләр бирү һәм бүлү турында" 2016 елның 30 декабрендәге 1556 номерлы карарын үтәү максатыннан һәм Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы белән Россия Федерациясе субъекты дәүләт хакимиятенең иң югары башкарма органы арасында төзелә торган 2017 елның 21 февралендәге 082-08-077 номерлы Россия Федерациясе субъекты бюджетына федераль бюджеттан субсидияләр бирү турында килешүгә нигезләнеп,

б о е р ы к б и р ә м:

1. Кушымта итеп бирелгән түбәндәгеләрне расларга:

1.1. "2017 – 2020 елларга Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперациясен үстерү" ведомство максатчан программасын;

1.2. "2017 – 2020 елларга Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперациясен үстерү" ведомство максатчан программасын гамәлгә ашыру кысаларында Авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативларының матди-техник базасын яхшыртуга грантлар бирү турында нигезләмәне;

2. Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының (алга таба – Министрлык) муниципаль районнардагы Авыл-хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәләре башлыкларына "2017 – 2020 елларга Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперациясен үстерү" программасында катнашу өчен авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативларын мәгълүмат белән тәэмин итүгә булышлык күрсәтергә.

3. Министрлыкның финанс бүлеге башлыгы М.А. Мәхмүтовка Авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативларының матди-техник базасын яхшыртуга грантлар бирү турында нигезләмәдә каралган һәм билгеләнгән лимитлар чикләрендәге акчаларның үз вакытында барып җитүен тәэмин итәргә.

4. Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының түбәндәге боерыкларын үз көчләрен югалткан дип танырга:

“2015 – 2017 елларга Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперациясен үстерү” ведомство максатчан программасын раслау турында” 2015 елның 12 октябрендәге 241/2-пр номерлы;

“ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының “2015 – 2017 елларга Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперациясен үстерү” ведомство максатчан программасын раслау турында” 2015 елның 12 октябрендәге 241/2-пр номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү хакында” 2015 елның 3 ноябрендәге 251/2-пр номерлы;

“ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының 2015 елның 12 октябрендәге 241/2-пр номерлы боерыгы белән расланган “2015 – 2017 елларга Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперациясен үстерү” ведомство максатчан программасын гамәлгә ашыру кысаларында Авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативларының матди-техник базасын яхшыртуга грантлар бирү турында нигезләмәгә 6 нчы кушымтага үзгәрешләр кертү хакында” 2016 елның 13 апрелендәге 75/2-пр номерлы.

5. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
урынбасары – министр М.Г.Әхмәтов

2017 елның 31.03. 70/2- пр номерлы
ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек
министрлыгы боерыгы белән расланды

# “2017 – 2020 ЕЛЛАРГА ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНДА АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫ КУЛЛАНУЧЫЛАР КООПЕРАЦИЯСЕН ҮСТЕРҮ”

# ВЕДОМСТВО МАКСАТЧАН ПРОГРАММАСЫ

Казан – 2017

**Эчтәлек**

"2017 – 2020 елларга Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперациясен үстерү" ведомство максатчан программасы паспорты 3
Кереш 7
1 бүлек. Проблемага характеристика һәм аны программалы алымнар белән хәл итүнең зарур булуын нигезләү 8
2 бүлек. Программаның төп максатлары һәм бурычлары 9
3 бүлек. Максат индикаторлары һәм көтелә торган нәтиҗәләр 10
4 бүлек. Программа чараларының исемлеге һәм тасвирламасы 12
5 бүлек. Программаны гамәлгә ашыру сроклары 16
6 бүлек. Программаны гамәлгә ашыруның социаль, икътисадый һәм экологик нәтиҗәләренә тасвирлама 16
7 бүлек. Бюджет акчаларының нәтиҗәле тотылуына бәя 17
8 бүлек. Программаның нәтиҗәлелегенә бәя бирү методикасы 17
9 бүлек. Программаны гамәлгә ашыру өчен бюджет ассигнованиеләре күләмен нигезләү 18
10 бүлек. Программаны гамәлгә ашыру белән идарә итү системасына тасвирлама 20
1 нче кушымта
2 нче кушымта
3 нче кушымта
4 нче кушымта
5 нче кушымта
6 нчы кушымта

**“2017 – 2020 елларга Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперациясен үстерү турында” ведомство максатчан программасы паспорты**

| | |
|---|---|
| Татарстан Республикасы ведомство максатчан программасының исеме | 2017 – 2020 елларга Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперациясен үстерү (алга таба – Программа) |
| Программаны эшләү өчен нигез | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “2013 – 2020 елларга Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарларын җайга салу” дәүләт программасын раслау турында” 2013 елның 8 апрелендәге 235 номерлы карары |
| Программаның заказчысы | Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы |
| Программаны төп эшләүчеләр | Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы |
| Программаның максаты | Авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперациясен авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләр, авыл җирендә хуҗалык итүнең кече формалары һәм кулланучылар җәмгыятьләре табышын арттыруның һәм аларның авыл җирендә яшәү сыйфатын яхшырту өчен эшләүче авыл хуҗалыгы продукциясен һәм азык-төлекне сату базарларына чыга алуын тәэмин итүнең төп механизмы буларак үстерү |
| Төп бурычлар | Куелган максатка ирешү өчен түбәндәге бурычларны хәл итәргә кирәк:<br>1. Авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләр тарафыннан кооперативлар әгъзалары хокукларында (ассоциацияләнгән әгъзалыктан тыш) кимендә 10 авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчене яки, әгәр табышларының 70 проценты авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативларының эшчәнлек төрләренә туры килә торган авыл хуҗалыгы продукциясен саклау өчен |

| | |
|---|---|
| | хәзерләп кую, саклау, эшкәртү һәм сату кебек эшчәнлек төрләрен башкару нәтиҗәсендә алынса, кулланучылар җәмгыятьләрен берләштерүче авыл хуҗалыгының кулланучылар эшкәртү кооперативлары һәм (яки) авыл хуҗалыгының сату кооперативлары төзелүне стимуллаштыру;<br>2. Авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләр тарафыннан җитештерелгән авыл хуҗалыгы продукциясен саклау өчен хәзерләп кую, транспортлау, саклау һәм эшкәртү өчен кооперативларның җитештерү куәтләрен булдыру һәм яңарту өчен шартлар тәэмин итү |
| Программаның күрсәткечләре | 1. Үзләренең матди-техник базаларын яхшыртучы авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативлары санын 40 берәмлеккә арттыру.<br>2. Өстәмә рәвештә даими 176 эш урынын булдырып, халыкның эш белән тәэмин ителүен арттыру. |
| Программа чараларына характеристика | Авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләр тарафыннан кооперативлар әгъзалары хокукларында (ассоциацияләнгән әгъзалыктан тыш) кимендә 10 авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчене яки, әгәр табышларының 70 проценты авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативларының эшчәнлек төрләренә туры килә торган авыл хуҗалыгы продукңиясен саклау өчен хәзерләп кую, саклау, эшкәртү һәм сату кебек эшчәнлек төрләрен башкару нәтиҗәсендә алынса, кулланучылар җәмгыятьләрен берләштерүче авыл хуҗалыгының кулланучылар эшкәртү кооперативларына һәм (яки) авыл хуҗалыгының сату кооперативларына грантлар бирүгә федераль бюджеттан һәм Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү.<br>Грантлар бирү: авыл хуҗалыгы терлеге сөтен, итен һәм кош-кортны, балыкны һәм аквакультура объектларын, бәрәңгене, гөмбәләрне, яшелчәләрне, җиләк-җимешләрне, шул исәптән кыргый үсә торганнарын саклау өчен хәзерләү, |

| | |
|---|---|
| | саклау, әзерләп кую, эшкәртү, сортларга аеру, чалу, беренчел эшкәртү, суыту һәм авыл хуҗалыгы продукциясен һәм аны эшкәртү продуктларын сатуга әзерләү буенча производство объектларын төзү, реконструкцияләү яки модернизацияләүгә;<br><br>авыл хуҗалыгы терлеге сотен, итен һәм кош-кортны, балыкны һәм аквакультура объектларын, бәрәңгене, гөмбәләрне, яшелчәләрне, җиләк-җимешләрне, шул исәптән кыргый үсә торганнарын саклау өчен хәзерләү, саклау, әзерләп кую, эшкәртү, сортларга аеру, чалу, беренчел эшкәртү, суыту, авыл хуҗалыгы продукциясен һәм аны эшкәртү продуктларын сатуга әзерләү, төяү, бушату, эшләп чыгарыла торган (җитештерелә торган һәм эшкәртелә торган) продукциянең сыйфатына һәм куркынычсызлыгына производство контроле һәм дәүләт ветеринария-санитария экспертизасын ясау лабораторияләрен җиһазлау (авыл хуҗалыгы продукциясенең сыйфатына лаборатория анализы ясау өчен җиһазлар сатып алу) өчен билгеләнгән производство объектлары өчен җиһазлар һәм техника сатып алуга һәм монтажлауга;<br><br>Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан раслана торган исемлек нигезендә авыл хуҗалыгы продукциясен һәм аны эшкәртү продуктларын транспортлау, ташыганда саклануын тәэмин итү һәм сату өчен махсуслаштырылган транспорт, фургоннар, прицеплар, ярымприцеплар, вагоннар, контейнерлар сатып алуга.<br><br>авыл хуҗалыгы терлеген, балыкны һәм аквакультураны саклау, әзерләп кую, эшкәртү, сортларга аеру, чалу, беренчел эшкәртү, сөтне, итне, кош-кортны, бәрәңгене, гөмбәләрне, яшелчәләрне, җиләк-җимешләрне, шул исәптән |

| | |
|---|---|
| | кыргый үсә торганнарын, суыту һәм авыл хуҗалыгы продукциясен һәм аны эшкәртү продуктларын сатуга, төяүгә, бушатуга һәм транспортлауга әзерләү өчен җиһазларны һәм техник чараларны лизингка алу шартнамәләре буенча кертемнәрнең бер өлешен (лизинг предметларының гомуми бәясеннән иң күбе 8 проңент күләмендә) түләүгә. |
| Гамәлгә ашыру сроклары | 2017 - 2020 еллар |
| Программаны үтәүчеләр | Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы |
| Финанслау күләмнәре һәм чыганаклары | Авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперациясен үстерү чараларын гамәлгә ашыру чыгымнарының күләме барлыгы 1000 млн.сум тәшкил итәчәк, еллар буенча түбәндәгечә:<br>2017 елда – 250 млн. сум,<br>2018 елда – 250млн. сум,<br>2019 елда – 250млн. сум,<br>2020 елда – 250млн. сум<br>федераль бюджеттан – 480 млн. сум, шулардан еллар буенча:<br>2017 елда – 120 млн. сум,<br>2018 елда – 120 млн. сум,<br>2019 елда – 120 млн. сум,<br>2020 елда – 120 млн. сум<br>Татарстан Республикасы бюджеты – 120 млн. сум, шулардан еллар буенча:<br>2017 елда – 30 млн. сум,<br>2018 елда – 30 млн. сум,<br>2019 елда – 30 млн. сум,<br>2020 елда – 30 млн. сум<br><br>кооперативларның үз акчалары – 400 млн.сум, шулардан еллар буенча:<br>2017 елда – 100 млн. сум,<br>2018 елда – 100 млн. сум,<br>2019 елда – 100 млн. сум,<br>2020 елда – 100 млн. сум |

| | |
|---|---|
| Ведомство максатчан Программасын тормышка ашырудан көтелә торган нәтиҗәләр һәм аның социаль-икътисадый нәтиҗәлелеге | Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперациясен үстерү. Эшкәртүче һәм сатучы кооперативлар белән авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләр арасында авыл хуҗалыгы продукциясен турыдан-туры авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләрдән һәм хуҗалык итүнең кече формаларыннан сатып алуга, элеге продукцияне эшкәртүгә һәм эшкәртелгән авыл хуҗалыгы продукциясен сатудан кергән керемнең бер өлешен авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативлары әгъзаларына тапшыруга юнәлтелгән озак вакытлы хуҗалык элемтәләрен кору.<br><br>Программаны гамәлгә ашыру түбәндәгеләрне тәэмин итәчәк:<br><br>- үзләрнең матди-техник базаларын яхшырту проектларын гамәлгә ашыручы кимендә 40 авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативын төзү;<br>- өстәмә даими 176 эш урынын булдырып, халыкның эш белән тәэмин ителүен арттыру;<br>Саклау һәм эшкәртү күләмнәрен түбәндәгечә арттыру:<br>- ит терлекчелеге продукциясен (кош-корт итеннән кала) - 71280 тоннага;<br>- сөтне – 44000 тоннага;<br>- бәрәңге һәм яшелчәләрне – 180000 тоннага;<br>- кош-корт итен – 9000 тоннага;<br>- җиләк-җимешләрне – 16000 тоннага |
| Идарә итү һәм тикшереп тору системасы | Программаны тормышка ашыру өчен Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы җаваплы була. |

# Кереш

Авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперациясенә дәүләт ярдәменең төп максаты инновацияләрне киң кертү хисабына авыл халкының тормыш дәрәҗәсен арттырудан гыйбарәт, бу Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясе халкын үзендә җитештерелгән азык-төлек белән тулысынча тәэмин итәргә, аның эш белән тәэминатын һәм керемнәрен арттырырга мөмкинлек биреп кенә калмыйча, үзебезнең авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләрне региональ, милли һәм дөнья базарларына конкурентлы төп товар китерүчеләргә әверелдерергә юл ачачак.

Программаның катнашучылары булу хокукына кимендә 10 авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчене берләштерүче авыл хуҗалыгы кулланучылар эшкәртү һәм авыл хуҗалыгы кулланучылар сату кооперативлары яки, әгәр табышларының 70 проценты авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативларының эшчәнлек төрләренә туры килә торган эшчәнлек төрләрен – авыл хуҗалыгы продукциясен сакларга хәзерләп кую, саклау, эшкәртү һәм сату – гамәлгә ашыру нәтиҗәсендә алынса, кулланучылар җәмгыятьләре (алга таба – кооперативлар) ия була..

## 1. Проблемага характеристика һәм аны программалы алымнар белән хәл итүнең зарур булуын нигезләү

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2012 елның 14 июлендәге 717 номерлы карары белән расланган 2013 – 2020 елларга авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарларын җайга салу дәүләт программасының (алга таба – Дәүләт программасы) төп максатлары белән беррәттән түбәндәге мөһим бурычлар бар:

- импортны алмаштыру шартларында эчке һәм тышкы базарларда республика авыл хуҗалыгы продукциясенең конкуренциягә сәләтен арттыру;
- авыл территорияләрен тотрыклы үстерү;
- авыл хуҗалыгында җир ресурсларыннан һәм башка ресурслардан файдалануны кире кайтару һәм аның нәтиҗәлелеген арттыру.

Шул ук вакытта Дәүләт программасына керүче “Хуҗалык итүнең кече формаларына ярдәм” ярдәмче программасы мөстәкыйль максат буларак хуҗалык итүнең кече формаларының авыл хуҗалыгы эшчәнлеген үстерү зарурлыгын һәм авыл җирендә халыкның яшәү сыйфатын яхшыртуны куя.

Авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләрнең (вертикаль буенча интеграцияләнгән кайбер эре структуралардан тыш) конкуренция көчле булган базарда эшләгәндә үз продукцияләрен сатудан кергән табышлары аның өчен соңгы кулланучы түләгән бәянең бик аз өлешен генә тәшкил итә. Продукцияне эшкәртү һәм сатуның барлык баскычларында алынган табыш авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчегә кадәр барып җитми, бу исә Дәүләт программасының максатларына ирешү һәм аның бурычларын хәл итү мөмкинлекләренә тискәре йогынты ясый.

Россия законнары нигезендә гражданнарның һәм эшкуарлык эшчәнлеге субъектларының кооперация процессы юридик затлар – кооперативлар төзү аркылы башкарыла. Авыл территорияләрендә төзелә торган төрле төрдәге кооперативлар, югарыда күрсәтелгән бурычтан тыш, үз әгъзаларының заем ресурсларыннан файдалана алуын тәэмин итү (авыл хуҗалыгы кулланучылар кредит кооперативлары), җитештерү һәм көнкүреш билгеләнешендәге продукция белән үз әгъзаларын тәэмин итү (кулланучылар җәмгыяте), төп фондлардан уртак файдалану аша эш белән тәэмин итү (авыл хуҗалыгы җитештерү кооперативлары) бурычларын хәл итәләр. Шулай итеп, авыл кооперациясенең барлык төрләрен үстерү авыл хуҗалыгы җитештерүенең файда китерүен тәэмин итүнең, авылда эш булуны саклап калуның, авыл халкының сатып алуларны башкару мөмкинлеген арттыруның һәм, иң мөһиме, авыл территорияләрен тотрыклы үстерүнең зарур шарты булып тора.

Эш башлаучы кооператорлар төрле җитди проблемалар белән очрашалар, шулардан иң мөһиме – башлангыч капиталның җитмәве, җәлеп ителгән финанс

ресурслары бәясенең югары булуы. Кооперативны төзү һәм аны үстерү аның әгъзаларыннан шактый зур күләмдә матди ресурсларны бергә туплауны, ә алар авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләрдә һәм авыл халкында гадәттә булмый, яисә заем акчаларын җәлеп итүне таләп итә, соңгысы кооперативның булачак әгъзаларын өчен зур йок булачак.

Идарә, икътисад, салым, бухгалтерлык, финанс һәм хокук мәсьәләләре буенча практикадагы тәҗрибәгә нигезләнгән һөнәри консультация бирү хезмәт күрсәтүләренә кытлык булу; кооперативлар менеджерларының һәм башка хезмәткәрләренең әзерлеге, өстәмә һөнәри белеме җитмәү аерым проблема булып тора.

Күрсәтелгән проблемаларны хәл итми торып, авыл җирендә эшләүче кооперативлар хосусый бизнес белән конкуренциядә сынаша алмаячак һәм, барыннан да бигрәк, эшчәнлекләрен башлый алмаячак яки аны туктатырга мәҗбүр булачак. Авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләргә дәүләт ярдәменең хәзерге вакытта федераль дәрәҗәдә каралган чаралары, тәҗрибә күрсәткәнчә, кооперацияне үстерергә стимул бирми, чонки әлеге чараларны күрү авыл хуҗалыгы җитештерүчесенең кооперативларда катнашуына, аларның капитализациясенә һәм күрсәтелә торган хезмәтләрнең күләме артуга бәйле түгел. Моннан тыш, гамәлдәге ярдәм чаралары халык кооперациясенең кулланучылар җәмгыятьләре кебек традицион институтларын җитәрлек дәрәҗәдә колачламый.

Үсеш инерция буенча баруын дәвам итсә, кооперативлар секторы үзенең сыйфатлы үсеше өчен чыганак тапмаячак, моның сәбәбе шул исәптән авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләрнең – хуҗалык итүнең кече формаларының бер-берсеннән ераклашуында күренә, алар исә авыл хуҗалыгы продукциясен эшкәртү куәтләренең җитәрлек булмавы аркасында системалы рәвештә тиешенчә керем ала алмыйлар.

## 2. Программаның төп максатлары һәм бурычлары

Программаны гамәлгә ашыру максаты авыл кооперациясенең барлык төрләрен һәм, иң элек, авыл җирендә авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперациясе системасын авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләрнең, хуҗалык итүнең кече формаларының, кулланучылар җәмгыятьләренең авыл хуҗалыгы продукциясен сату базарларына чыга алуын тәэмин итүнең, авыл җирендә яшәү сыйфатын яхшыртуның төп механизмы буларак үстерүдән гыйбарәт.

Программа кысаларында түбәндәге бурычлар хәл ителәчәк:

– авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләрнең, хуҗалык итүнең кече формаларын да кертеп, авыл хуҗалыгы кулланучылар эшкәртү һәм сату кооперативларын төзүен һәм авыл җирендә кулланучылар кооперациясен үстерүне стимуллаштыру;

– кооперативның матди-техник базасын булдыру һәм модернизацияләү өчен шартлар тәэмин итү – производство биналарын, төзелмәләрен, бүлмәләрен, цехларын булдыру (сатып алу, ремонтлау, модернизацияләү, профилен үзгәртү, төзү), чыгарыла торган (җитештерелә торган, эшкәртелә торган һ.б.ш.) продукциянең сыйфатына һәм куркынычсызлыгына производство контроле һәм дәүләт ветеринария-санитария экспертизасын ясау лабораторияләрен җиһазлау (авыл хуҗалыгы продукциясенең сыйфатына лаборатория анализын ясау өчен җиһазлар сатып алу), ит, кош-кортны саклау өчен хәзерләп кую, саклау, эшкәртү, сортларга аеру, чалу, беренчел эшкәртү һәм суыту, авыл хуҗалыгы продукциясен сатуга хәзерләү, төяү, бушату, транспортлау өчен билгеләнгән җиһазлар сатып алуга, авыл хуҗалыгы продукциясен ташу өчен махсуслаштырылган транспорт, фургоннар, прицеплар, вагоннар, модульләр сатып алу (шул исәптән лизинг кулланып).

## 3. Максат индикаторлары һәм көтелә торган нәтиҗәләр

Программаны гамәлгә ашыруның төп нәтиҗәсе чимал җитештерүдән башлап әзер (әзерләп куелган һәм (яки) яңадан эшкәртелгән) авыл хуҗалыгы продукциясен сатуга кадәр башкарыла торган бердәм технологик процессның үзара бәйләнгән буыннарын авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләрне кооперативларга берләштереп үстерүдән гыйбарәт була.

Авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативларына матди-техник базаны яхшыртуга грант ярдәме буенча чараларны гамәлгә ашыруның турыдан-туры нәтиҗәсе эшкәртүче һәм сатучы кооперативларның саны артуда, авыл җирендә эш урыннары саны артуда, авылда кадрлар төпләнеп калуда һәм авыл халкының исәбе тотрыклануда күренәчәк.

Куелган бурычларны хәл итүнең максат индикаторлары 1 нче таблицада китерелде.

1 нче таблица

Авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативларына матди-техник базаны яхшыртуга грант ярдәме буенча чараларның пландагы индикаторлары

| Индикаторның исеме | Исәп берәмлеге | 2017 | 2018 | 2019 | 2020 |
|---|---|---|---|---|---|
| Матди-техник базаларын дәүләт ярдәме белән яхшырткан авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативларының саны | берм. | 10 | 10 | 10 | 10 |

Индикаторларны исәпләп чыгару өчен кирәкле абсолют күрсәткечләр 2 нче таблицада китерелде.

2 нче таблица

Авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативларына матди-техник базаны яхшыртуга грантлар бирү чараларын гамәлгә ашыру өчен федераль бюджет һәм Татарстан Республикасы бюджеты ассигнованиеләре күләме

| Күрсәткеч | Исәп берәмлеге | 2017 | 2018 | 2019 | 2020 |
|---|---|---|---|---|---|
| Авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативларына матди-техник базаны яхшыртуга грантлар бирү чараларын гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы бюджеты ассигнованиеләре күләме | млн. сум | 10 | 10 | 10 | 10 |

Программаны гамәлгә ашыру нәтиҗәсе 3 нче таблицада китерелгән сан күрсәткечләре белән билгеләнә, алар объективлык, дөреслек, ачыклык һәм нисбәтлелек критерийларына җавап бирә.

3 нче таблица

Программаны гамәлгә ашырудан көтелә торган нәтиҗәләр

| Күрсәткечнең исеме | Исәп берәмлеге | 2017 | 2018 | 2019 | 2020 |
|---|---|---|---|---|---|
| Матди-техник базаларын дәүләт ярдәме белән яхшырткан авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативларының саны | берәмлек | 10 | 10 | 10 | 10 |
| Эш урыннары булдыру | берәмлек | 44 | 44 | 44 | 44 |
| Сатылган авыл хуҗалыгы продукциясе күләме артымы | % | 10 | 10 | 10 | 10 |

2017 – 2020 елларда 40 кооперативның матди-техник базасын булдыру һәм яхшырту түбәндәгеләргә мөмкинлекләр бирәчәк:

1. Кооперативлар эшендә катнашу хисабына авыл хуҗалыгы продукциясен саклау һәм эшкәртүнең заманча технологияләреннән авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләрнең файдалана алуын тәэмин итәргә;
2. Авыл хуҗалыгы чималын саклау һәм эшкәртү өчен җитештерү базалары булмаган авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләрнең финанс чыгымнарын

авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләрнең җитештерү белән бәйле булмаган югалтуларын азайту хисабына киметергә;

3. Сыйфатлы авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерүне стимуллаштырырга;

4. Авыл хуҗалыгы продукциясе базарында кече формалар эшчәнлегенең конкуренциягә сәләтле булуын арттырырга;

5. Авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләрнең һәм авыл халкының керемнәрен арттырырга;

6. Авыл территорияләрен тотрыклы үстерү һәм үзләштерү, шулай ук авыл җирендә халыкны урнаштыруның хәзерге системасын саклап калу өчен шартлар тудырырга;

7. Хуҗалык итүнең кече формаларында, шул исәптән шәхси ярдәмче хуҗалыкларда, авыл халкының эш белән тәэмин ителүен арттыру һәм авыл җирендәге гадәти яшәү рәвешләрен саклап калу рәвешендә социаль нәтиҗә алырга.

## 4. Программа чараларының исемлеге һәм тасвирламасы

4.1. Программаны гамәлгә ашыру механизмы муниципаль берәмлекләрнең кооперативларга грантлар бирү буенча чараларны башкарганда барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслауга федераль бюджеттан һәм Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирүдән гыйбарәт.

4.2. Грант рәвешендә дәүләт ярдәмен алуда кооперативларның түбәндәге бер яки берничә авыл хуҗалыгы продукциясе төрен җыю, кабул итү, саклау, хәзерләп кую, сатуга әзерләү, сортларга аеру, төрле дәрәҗәдә эшкәртү эшчәнлегенә өстенлек бирелә:

ит терлекчелеге продукциясен, чалу цехларын да кертеп – 12 берәмлек (Африка дуңгыз чумасы таралу куркынычы зур булган төбәкләрдәге дуңгызчылыктан тыш);

сөт – 8 берәмлек;

бәрәңге һәм яшелчәләр – 6 берәмлек;

кош-кортларны чалу, эшкәртү буенча гамәлдәге авыл хуҗалыгы эшкәртү кулланучылар кооперативларын реконструкцияләү – 6 берәмлек;

җиләк-җимеш һәм кыргый җиләк-җимеш – 8 берәмлек.

4.3. Программа Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгында каралырга һәм сайлап алынырга тиеш.

4.4. Программаның катнашучыларын кимендә 10 авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчене берләштерүче гамәлдәге яки төзелә торган авыл хуҗалыгы кулланучылар эшкәртү һәм авыл хуҗалыгы кулланучылар сату кооперативлары яки, әгәр табышларының 70 проценты авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативларыныц эшчәнлек төрләренә туры килә торган эшчәнлек төрләрен – авыл хуҗалыгы продукциясен саклау өчен хәзерләп кую,

саклау, эшкәртү һәм сату – гамәлгә ашыру нәтиҗәсендә алынса, кулланучылар җәмгыятьләре тәшкил итә.

Авыл хуҗалыгы кооперативларын сайлап алуны, Россия Федерациясе норматив актларына нигезләнеп, Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы (алга таба – Министрлык) тарафыннан төзелгән конкурс комиссиясе башкара.

4.5. Конкурс буенча сайлап алуда катнашу өчен кооператив җитәкчесе, Программада катнашучыларга карата куелган таләпләргә туры килүен раслый торган документларны һәм ике нөсхәдә теркәлгән документларның исемлеген беркетеп, конкурс комиссиясенә заявка бирә. Документларны кабул итү турында тамга салынган бер нөсхә кооперативта кала.

Конкурс буенча сайлап алуда катнашу өчен заявка биргәндә кооператив җитәкчесе кооператив әгъзаларыннан һәм кооператив җитәкчелегеннән аларның персональ мәгълүматларын эшкәртү һәм бирүгә ризалыгын да тапшыра.

Гариза бирүче конкурсның теләсә кайсы баскычында үзенең заявкасын кире алырга хокуклы. Моның өчен кооператив җитәкчесе конкурс комиссиясенә тиешле гариза бирә.

4.6. Программада катнашучыларны сайлап алу конкурсы түбәндәге баскычларны үз эченә алырга тиеш:

конкурс турында һәм аны үткәрү сроклары хакында халыкка хәбәр итү;

Программада катнашучыларны сайлап алуга заявкалар кабул итү;

кооператив үстерү буенча булган мөмкинлекләрен өйрәнү өчен Министрлык һәм Татарстан фермерлары һәм крестьян хуҗалыклары ассоциациясе вәкилләренең кооперативка (конкурста катнашучы) барып кайтуы (заявка кабул итү датасы белән турыдан-туры сөйләшү үткәрү датасы арасында);

конкурс комиссиясенең заявкалар турында фикер алышуга һәм конкурсантларны турыдан-туры сөйләшүгә кертү мәсьәләсенә багышланган утырышлары;

конкурс комиссиясе карарларын (беркетмәдән өземтәләрне) тиешле материалларны тапшырмаган гариза бирүчеләргә комиссия секретаре тарафыннан тапшыру;

кооператив җитәкчесе, проектка ярдәм итү йөкләмәсен алган банк учреждениесе вәкиле (әгәр кооператив кредит акчаларын җәлеп итүне күз алдында тоткан очракта), проектның поручительләре һәм проект гамәлгә ашырылачак җирлекнең җирле үзидарә органы җитәкчесе белән турыдан-туры сөйләшү;

гариза бирүчеләргә комиссия секретаренең конкурс комиссиясе карарларын (беркетмәдән өземтәләр) тапшыруы.

4.7. Программада катнашучыларны сайлап алу конкурсы җәмәгатьчелек өчен ачык рәвештә узарга тиеш.

Конкурс комиссиясе составына Татарстан Республикасы дәүләт хезмәткәрләре һәм муниципаль хезмәткәрләр булып тормаган кимендә 50 процент әгъза кертелергә тиеш. Аның составына шулай ук иҗтимагый оешмалар, берәмлекләр һәм берләшмәләр вәкилләрен, авыл хуҗалыгы кооперативлары ревизия берлекләре җитәкчеләрен кертү тәкъдим ителә.

Конкурс комиссиясе утырышларына хокук саклау һәм күзәтчелек органнары вәкилләрен, җирле үзидарә органнары вәкилләрен чакырырга, шулай ук конкурс комиссиясе утырышларына массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләренең, юридик затларның һәм индивидуаль эшкуарларның керә алуын тәэмин итәргә тәкъдим ителә.

4.8. Кооперативларның матди-техник базасын яхшыртуга грант дигәндә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “2013 – 2020 елларга Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чималы һәм азык-төлек базарларын җайга салу” дәүләт программасын раслау турында” 2013 елның 8 апрелендәге 235 номерлы карары белән расланган “2013 – 2020 елларга Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарларын җайга салу” дәүләт программасы нигезендә дәүләт ярдәменең башка юнәлешләре кысаларында капланмый торган чыгымнарны финанслашу өчен кооперативның Россия кредит оешмасында ачылган счетына федераль бюджеттан һәм Татарстан Республикасы бюджетыннан яки җирле бюджеттан күчерелә торган акчалар аңлашыла.

Программада катнашучы грантны түбәндәге максатларга тота ала:

сөтне, авыл хуҗалыгы терлеге, кош-корт итен, балыкны һәм аквакультураны, бәрәңгене, гөмбәләрне, яшелчәләрне, җимешләрне һәм җиләкләрне, шул исәптән кыргый үсә торганнарын саклау өчен хәзерләү, саклау, әзерләп кую, эшкәртү, сортларга аеру, чалу, беренчел эшкәртү, суыту һәм авыл хуҗалыгы продукциясен һәм аны эшкәртү продуктларын сатуга әзерләү буенча производство объектларын төзү, реконструкцияләү яки модернизацияләүгә;

сөтне, авыл хуҗалыгы терлеге, кош-корт итен, балыкны һәм аквакультураны, бәрәңгене, гөмбәләрне, яшелчәләрне, җимешләрне һәм җиләкләрне, шул исәптән кыргый үсә торганнарын саклау өчен хәзерләү, саклау, әзерләп кую, эшкәртү, сортларга аеру, чалу, беренчел эшкәртү, суыту, авыл хуҗалыгы продукциясен һәм аны эшкәртү продуктларын сатуга әзерләү, төяү, бушату, эшләп чыгарыла торган (җитештерелә торган һәм эшкәртелә торган) продукциянең сыйфатына һәм куркынычсызлыгына производство контроле һәм дәүләт ветеринария-санитария экспертизасын ясау лабораторияләрен җиһазлау (авыл хуҗалыгы продукциясенең сыйфатын анализлау өчен җиһазлар сатып алу) өчен билгеләнгән производство объектлары өчен җиһазлар һәм техника сатып алуга һәм монтажлауга. Күрсәтелгән җиһазларның һәм техниканың исемлеге

Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгының “Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2016 елның 30 декабрендәге 1556 номерлы карары белән расланган Агросәнәгать комплексын үстерүнең региональ программаларының максат күрсәткечләренә ирешүгә ярдәм итү өчен Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына федераль бюджеттан субсидияләр бирү һәм бүлү кагыйдәләрендә каралган документларны раслау турында” 2017 елның 31 гыйнварындагы 45 номерлы боерыгы белән (алга таба – Россия Авыл хуҗалыгы министрлыгы) расланган.

авыл хуҗалыгы продукциясен һәм аны эшкәртү продуктларын транспортлау, ташыганда саклануын тәэмин итү һәм сату өчен махсуслаштырылган транспорт, фургоннар, прицеплар, ярымприцеплар, вагоннар, контейнерлар сатып алуга. Күрсәтелгән техника исемлеге Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан раслана;

сөтне, авыл хуҗалыгы терлеге, кош-корт итен, балыкны һәм аквакультураны, бәрәңгене, гөмбәләрне, яшелчәләрне, җимешләрне һәм җиләкләрне, шул исәптән кыргый үсә торганнарын саклау өчен хәзерләү, саклау, әзерләп кую, эшкәртү, сортларга аеру, чалу, беренчел эшкәртү, суыту һәм авыл хуҗалыгы продукциясен һәм аны эшкәртү продуктларын сатуга әзерләү, төяү, бушату һәм транспортлау өчен җиһазларны һәм техник чараларны лизингка алу шартнамәләре буенча кертемнәрнең бер өлешен (лизинг предметларының гомуми бәясеннән иң күбе 8 процент күләмендә) түләүгә.

4.9. Конкурс комиссиясе кооператив чыгымнарының җентекле планын раслый.

Чыгымнар планының һәр статьясы грант һәм үз акчалары исәбеннән түбәндәге нисбәттә берьюлы финансланырга тиеш: грант исәбеннән иң күбе 60 процент һәм кооперативның үз акчаларыннан кимендә 40 процент.

Чыгымнар планына үзгәрешләр кертү таләп ителгән очракта, күрсәтелгән үзгәрешләр конкурс комиссиясе тарафыннан килештерелә һәм раслана. Үзгәрешләр проектның куәтен киметерлек булырга тиеш түгел.

4.10. Матди-техник базаны яхшыртуга алынган грант расланган чыгымнар планы нигезендә кооператив тарафыннан 18 ай эчендә тотылып бетә.

4.11. Авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативлары рәисләре квартал саен Министрлыкка Министрлык раслаган форма буенча матди-техник базаны яхшыртуга грантлар акчаларының максатчан тотылуы турында хисап тапшыралар.

Тапшырыла торган хисапларның дөреслеген Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Татарстан Республикасы муниципаль районнарындагы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәләре тикшереп тора.

4.12. Министрлык акчаларның кооперативларга барып җитүен һәм алар тарафыннан максатчан тотылуын тикшереп торуны тәэмин итә.

Кооперативның матди-техник базасын яхшыртуга алынган грант Программада катнашучы тарафыннан максатчан билгеләнешендә файдаланылмаса, аның суммасына тигез акчалар Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә тиешле бюджетка кире кайтарылырга тиеш.

4.13. Грант ярдәме акчаларының югалмавын һәм максатчан файдалануын тәэмин итү максатларында Министрлык Программаны гамәлгә ашыру механизмнарына кагылышлы норматив хокукый актларында Программада катнашучының үз йөкләмәләрен тәэмин итүенең финанс чыганакларын билгели.

4.14. Программада катнашучылар авыл кооперативларының региональ һәм бөтенроссия съездларын, кооперативларның эшчәнлек юнәлешләре буенча фәнни-гамәли конференцияләрне, тематик күргәзмәләрне әзерләүдә һәм үткәрүдә катнашалар, шулай ук консультацияләр һәм кооператив кадрларының квалификациясен күтәрү буенча уку курсларын үткәрү юлы белән кооперативлар әгъзаларының белем дәрәҗәсен даими күтәреп торуны максат итеп куялар.

Министрлык, ведомство буйсынуындагы агрария мәгариф учреждениеләре базасында уку-укыту программалары буенча уку мөмкинлекләрен биреп, Программада катнашучыларга булышлык күрсәтә.

## 5. Программаны гамәлгә ашыру сроклары

Программа 2017-2020 елларда гамәлгә ашырыла.

## 6. Программаны гамәлгә ашыруның социаль, икътисадый һәм экологик нәтиҗәләренә тасвирлама

6.1. Программаның максатка ирешүдә керткән өлешенә гомуми бәя:

- Программаны гамәлгә ашыру авыл хуҗалыгы өлкәсендә Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының стратегик максатларына, әйтик, үзебезнең авыл хуҗалыгы продукциясенең конкурентлыкка сәләтен финанс тотрыклылыгына һәм авыл хуҗалыгын модернизацияләүгә нигезләнеп артыруга; авыл территорияләрен тотрыклы үстерүгә, авыл халкының эш белән тәэмин ителү һәм яшәү дәрәҗәсен күтәрүгә ирешергә ярдәм итәчәк.

6.2. Программаны гамәлгә ашыруның социаль, икътисадый һәм экологик нәтиҗәләре.

Программа чараларын гамәлгә ашыру нәтиҗәсендә шәхси ярдәмче һәм крестьян фермер хуҗалыкларының, кече һәм урта авыл хуҗалыгы оешмаларының авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерү һәм сату күләмнәренең артуы планлаштырыла.

6.3. Программаны гамәлгә ашыргандагы куркынычлыкларга бәя.

Чынбарлыкта ирешелгән Программа нәтиҗәләренең алдан планлаштырылганнарыннан үзгә булуына йогынты ясарлык тышкы шартларга һәм куркынычлыкларга түбәндәгеләр керә:

1. Азык-төлек товарларына бәяләрнең, шул исәптән импорт продукциясе керү хисабына, иң түбәнгә төшүе;
2. Төзелеш материалларына, техникага һәм җиһазларга бәяләрнең инфляция темпларына бәйле көтелә торган күтәрелүеннән тагы да күбрәк артуы;
3. Форс-мажор шартлар.

Күрсәтелгән куркынычлыклар кооператив эшчәнлегенә бәяле түгел. Шуңа күрә аларның булуын алдан фаразлап кую мөмкин түгел.

## 7. Бюджет акчаларының нәтиҗәле тотылуына бәя

7.1. Программаның икътисадый нәтиҗәлелеге түбәндәге күрсәткечләр буенча бәяләнә:

4 нче таблица

Программа буенча бюджет акчаларын тоту нәтиҗәлелеге

| Күрсәткечләр | Исәп берәмлеге | 2017 | 2018 | 2019 | 2020 | 2017-2020 еллар |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1. Россия Федерациясе бюджетыннан субсидияләр күләме | млн. сум | 120 | 120 | 120 | 120 | 480 |
| Татарстан Республикасы бюджеты | млн. сум | 30 | 30 | 30 | 30 | 120 |
| Кооперативлар акчалары | млн. сум | 100 | 100 | 100 | 100 | 400 |
| Барлыгы: | млн. сум | 250 | 250 | 250 | 250 | 1000 |
| 2. Матди-техник базаларын грантлар хисабына яхшырткан кооперативларның саны | берәмлек | 10 | 10 | 10 | 10 | 40 |
| 3. Өстәмә эш урыннары булдыру - | берәмлек | 44 | 44 | 44 | 44 | 176 |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| барлыгы | | | | | | |

Программаның гамәлгә ашырылуы нәтиҗәлелегенә бәя бирүне максат индикаторларына таянып башкару максатка ярашлы булачак, аларның зурлыгын исә килешүләрдә билгеләү тәкъдим ителә.

**8. Программаның нәтиҗәлелегенә бәя бирү методикасы**

Программаның нәтиҗәлелегенә бәя бирү авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативлары – Программаның җиңүчеләре тарафыннан тапшырыла торган хисапка нигезләнеп башкарыла. Хисап бирү формалары Министрлык тарафыннан “Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2016 елның 30 декабрендәге 1556 номерлы карары белән расланган Агросәнәгать комплексын үстерүнең региональ программаларының максат күрсәткечләренә ирешүгә ярдәм итү өчен Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына федераль бюджеттан субсидияләр бирү һәм бүлү кагыйдәләрендә каралган документларны раслау турында” 2017 елның 31 гыйнварындагы 45 номерлы боерыгы белән раслана.

Программа чараларының гамәлгә ашырылуы нәтиҗәлелеге шулай ук дәүләтнең статистик һәм ведомствоның тармак формалары буенча бирелгән хисаплылыкка ясалган анализны исәпкә алып билгеләнә:

1-кооператив формасы – “Авыл хуҗалыгы эшкәртү кулланучылар кооперативы эшчәнлеге турында белешмәләр”;

2-кооператив формасы – “Тәэмин итү – сату авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативы эшчәнлеге турында белешмәләр”;

4-кооператив формасы – “Авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативлары (эшкәртү, тәэмин итү – сату һәм кредит кооперативларыннан тыш) эшчәнлеге турында белешмәләр”;

П-2 формасы – “Ивестиция эшчәнлеге турында белешмәләр”;

П-4 формасы – “Хезмәткәрләрнең саны һәм хезмәт хакы турында белешмәләр”;

П-6 формасы – АПК “Агросәнәгать комплексы оешмалары эшчәнлегенең тармак күрсәткечләре турында хисап”;

П-10 формасы – АПК “Максатчан финанслау чаралары турында хисап”;

1-спрК формасы – “Авыл хуҗалыгы кулланучылар кредит кооперативлары эшчәнлеге нәтиҗәләре турында мәгълүмат”;

1-спр формасы – “Авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативлары (кредит кооперативларыннан тыш) эшчәнлеге нәтиҗәләре турында мәгълүмат”;

1-торг формасы – “Кулланучылар җәмгыятьләренең сәүдә эшчәнлеге турында белешмәләр”;

2 форма – “Авыл хуҗалыгы продуктларын, кыргый үсә торган чималны, терлекчелек чималын һәм башка чималны сатып алу турында белешмәләр”;

1-П формасы – “Кулланучылар кооперациясе системасында продукция җитештерү турында белешмәләр”.

Сыйфат алымы: күрсәткечләрнең планлаштырылган зурлыкларына һәм максат индикаторларына ирешү

## 9. Программаны гамәлгә ашыру өчен бюджет ассигнованиеләре күләмен нигезләү

Программаны гамәлгә ашыру өчен бюджет ассигнованиеләре күләмнәрен нигезләү кооперативларның матди-техник базасын яхшыртуның пилот проектларын, алар түбәндәге юнәлешләр буенча авыл хуҗалыгы продукциясен эшкәртүне һәм логистика үзәкләрен үстерүне күз алдында тота, гамәлгә ашыру мөмкинлеген тәэмин итү зарурлыгыннан чыгып бирелде:

1. Яшелчәләрне һәм бәрәңгене кабул итү, саклау, юу, сортларга аеру, фасовкалау буенча логистика үзәген төзү һәм технологик җиһазлау – продукцияне кабул итү буенча елына 30 мең тонналы, саклау буенча 12 мең тонналы куәтле 6 данә (алга таба – Логистика үзәге)*. – 240,0 млн. сум.

2. Җитештерүчәнлеге елына 5500 тонна булган сөт эшкәртү мини-заводын, инфраструктураны һәм коммуникацияләрне исәпкә алмыйча, тулысынча комплектацияләү (алга таба – 8 данә Мини-завод)* – 320,0 млн. сум.

3. Терлекчелектә симертү буенча авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативларын төзү һәм үстерү, ит комбинатларын технологик җиһазлауны булдыру һәм яхшырту – тәүлегенә 25 – 30 баш терлек чалу һәм тәүлегенә 22,5 тонна ит эшкәртү куәте белән 12 данә, монда инфраструктура һәм коммуникацияләр исәпкә алынмый, (алга таба – ит комбинаты) – 480 млн. сум*.

4. Кош-корт үстерү, чалу һәм эшкәртү буенча эшли торган авыл хуҗалыгы эшкәртү кулланучылар кооперативларын реконструкцияләү – 3000 тонна кош-корт итенә каралган 6 данә – 240,0 млн. сум.

5. Җиләк-җимешләрне, кыргый җиләкләрне саклау, эшкәртү – 1 данә – 320 млн. сум.

Шул ук вакытта түбәндәге шартлар үтәлә:

1. Грант күләме проект буенча гомуми чыгымнарның 60 процентыннан артык булырга тиеш түгел;
2. Федераль бюджет белән Татарстан Республикасы бюджеты акчалары нисбәте 70 процентка 30 процент булырга тиеш.

| | 2017 | 2018 | 2019 | 2020 |
|---|---|---|---|---|
| Финанслауныц берләштерелгән күләме, млн.сум | 250 | 250 | 250 | 250 |
| Россия Федерациясе бюджетыннан субсидияләр күләме , млн.сум | 120 | 120 | 120 | 120 |
| Татарстан Республикасы бюджеты, млн.руб | 30 | 30 | 30 | 30 |
| Кооперативлар акчалары, | 100 | 100 | 100 | 100 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| млн.сум | | | | |
| Грант алучы кооперативлар саны | 10 | 10 | 10 | 10 |
| Бер кооперативка уртача грант күләме, млн. сум | 15 | 15 | 15 | 15 |

*Күрсәтелгән куәттәге производстволарны комплектацияләүнең уртача бәясе, 2016 ел бәяләрендә

Программа чараларын гамәлгә ашыру өчен түбәндәгеләр таләп ителә:

тиешле ел бәяләрендә алганда, кооперативлар акчаларын да кертеп, финанслауның барлык чыганакларыннан 1000 млн.сум, шул исәптән:

2017 елда – 250 млн. сум; 2018 елда – 250 млн. сум;  2019 елда – 250 млн. сум; 2020 елда – 250 млн. сум.

Программа чараларын федераль бюджеттан һәм Татарстан Республикасы бюджетыннан, шулай ук бюджеттан тыш чыганаклардан финанслау күләмнәре тиешле финанс елына һәм план чорына бюджетлар әзерләгәндә төгәлләштерелергә мөмкин.

## 10. Программаны гамәлгә ашыру белән идарә итү системасына тасвирлама

Программаны гамәлгә ашыру белән идарә итү, административ, контроль функцияләрен гамәлгә ашыруга, Программаның үтәлешенә мониторинг һәм анализ ясауга кооператив оешмаларны, ассоциацияләрне һәм берлекләрне киң җәлеп итеп, идарә итүнең, хезмәттәшлекнең һәм вәкаләтләр бирүнең дәүләт һәм кооператив формалары партнерлыгы принципларына нигезләнеп башкарыла.

Программага идарә итүне оештыру һәм аны гамәлгә ашыру барышын тикшереп тору Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы тарафыннан башкарыла.

2017 елның 31.03. 70/2- пр
номерлы ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-
төлек министрлыгы боерыгы белән
расланган программага
1 нче кушымта

Тәүлегенә 30 баш терлек чалу һәм тәүлегенә 22,5 тонна ит эшкәртү куәте булган ит комбинатын төзү һәм технологик җиһазлау бәясен алдан исәпләп чыгару

| № т/б | Исеме | Бәясе, мең. сум |
|---|---|---|
| 1. | **Төзелеш-монтаж эшләренә, шул исәптән исәптән түбәндәгеләрне төзү өчен тотылган чыгымнар (мец сум):** | 18,400 |
| | *а/ терлекне чалу алдыннан асрау боксларын* | |
| | *б/ чалу цехын* | |
| | *в/ ит суыту һәм катыру камераларын* | |
| | *г/ ярдәмче бүлмәләрне* | |
| | *- администрация-көнкүреш бүлмәләре;* | |
| | *- склад бүлмәләре* | |
| | *- тире тозлау һәм аларны саклау өчен каралган бүлмәләрне* | |
| | *д/ ит эшкәртү цехларын* | |
| | *е) эчке юлларны салу һәм территорияне төзекләндерү* | |
| 2. | **Технологик җиһазларга тотыла торган чыгымнар, шул исәптән:** | 11,200 |
| | Су эчерү системасы | |
| | Тирес җыю системасы | |
| | Вентиляция системасы | |
| | Су белән тәэмин итү һәм канализация системасы | |
| | Чалу өчен каралган җиһазлар | |
| | Эчәк чималы субпродуктларын беренчел эшкәртү һәм тирене тозлау өчен каралган җайланма | |
| | Колбасалар һәм ярымфабрикатлар җитештерү җайланмалары | |
| | Суыту һәм катыру җиһазлары | |
| 3. | **Техника сатып алу чыгымнары, шул исәптән:** | 8,800 |
| | Технологик транспорт (Трактор МТЗ 1221+фронталь погр. + кара) | |
| | Суытылган һәм катырылган итне ташу өчен суыткычлы рефрижераторлар (3 берәмлек) | |
| | Терлекне китерү өчен каралган транспорт | |
| | **Барлык чыгымнар (инфраструктура һәм коммуникацияләр төзүне исәпкә алмыйча )** | |
| *4.* | **Инфраструктура булдыру һәм коммуникация китерү чыгымнары, шул исәптән:** | 5,600 |
| | *- килү юлларын төзү;* | |
| | *- техник шартлар булдыру;* | |
| | *- янгын-сак сигнализациясе һәм саклау максатыннан видеокүзәтү системасы* | |
| | *- электртапшыргыч линияләр, трансформатор подстанциясе һәм резерв электр бирү чыганагы* | |
| | *- чистарту корылмалары;* | |

| | | |
|---|---|---|
| | *- су китерү һәм су алып китү линияләре булган суэтем башнясы* | |
| **БАРЛЫГЫ мең сум** | | 44,00 |

2017 елның 31.03. 70/2 пр
номерлы ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-
төлек министрлыгы боерыгы белән
расланган программага
2 нче кушымта

Җитештерүчәнлеге елына 5500 тонна булган сөт эшкәртү мини-заводын төзү һәм технологик җиһазлау бәясен алдан исәпләп чыгару

| № т/б | Исеме | Бәясе, мең сум |
|---|---|---|
| **1.** | **Төзелеш-монтаж эшләренә чыгымнар (мең сум), шул исәптән:** | 16,200 |
| | *а/ 3 сөт суыткычны урнаштыру өчен 3 сөт җыю пункты бүлмәләре* | |
| | *б/ лабораториясе булган сөт кабул итү бүлеге* | |
| | *в/сөт эшкәртү һәм савытларга тутыру цехы* | |
| | *г/ суыту камералары* | |
| | *д/ ярдәмче бүлмәләре:* | |
| | *- администрация-көнкүреш бүлмәләре;* | |
| | *- склад бүлмәләре* | |
| | *- техника өчен лапас* | |
| | *д) эчке юлларны салу һәм территорияне төзекләндерү* | |
| **2.** | **Технологик җиһазларга тотыла торган чыгымнар (мең сум), шул исәптән:** | 14,800 |
| | Кабул итү пунктларына урнаштыру өчен 1,5 тонна сыйдырышлы суыткыч танклар (3 данә) | |
| | Кабул иткәндә үлчи торган үлчәүләр | |
| | 5 тонналык үзеннән-үзе чистаручы суыткыч танк (сөт заводыныц үзендә) | |
| | Технологик җиһаз (сөт аеру сепараторы, ванналар, насослар, сөтүткәргечләр, компрессор, чистарткыч, пастеризатор, сөт һәм сөт өстен савытларга тутыру буенча ярымавтомат линия, эремчек һәм йомшак сортлы сыр җитештерү линиясе). | |
| | Вентиляция системасы | |
| | Су белән тәэмин итү һәм канализация системасы | |
| | Суыткыч җиһазлар | |
| **3.** | **Техника сатып алу чыгымнары (мең сум), шул исәптән:** | 9,100 |
| | Әзер продукцияне ташу өчен суыткыч рефрижератор | |
| | Сөт җыю пунктларыннан сөтне алып килү өчен транспорт | |
| | **Барлык чыгымнар (инфраструктураны һәм коммуникаңияләрне исәпкә алмыйча ), мең сум** | 40,100 |
| *4.* | **Инфраструктура булдыру һәм коммуникаңия китерү чыгымнары (мең сум), шул исәптән:** | 3,9 |
| | *- электртапшыргыч линияләр, трансформатор подстанциясе һәм резерв электр бирү чыганагы* | |
| **Инфраструктура һәм коммуникацияләрне исәпкә алып, җптештерүчәнлеге елына 1100 тонналык тулысынча җпһазланган сөт эшкәртү мини-заводының бәясе** | | 44,00 |

2017 елның 31.03. 70/2 пр
номерлы ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-
төлек министрлыгы боерыгы белән
расланган программага
3 нче кушымта

Яшелчәләрне һәм бәрәңгене кабул итү, саклау, юу, сортларга аеру, фасовкалау буенча елына 30 мең тонна кабул итү куәте, 4 мең тонна саклау куәте булган логистика үзәген төзү һәм технологик җиһазлау бәясен алдан исәпләп чыгару

| № т/б | Исеме | Бәясе, мең сум |
|---|---|---|
| **1.** | **Төзелеш-монтаж эшләренә чыгымнар, шул исәптән түбәндәгеләрне төзү өчен тотылган чыгымнар (мең сум):** | 15,200 |
| | *а/ лабораторияләре булган кабул итү һәм сортларга аеру бинасын* | |
| | *б/ яшелчә саклау урыннарын* | |
| | *в/ бәрәңге саклау урыннарын* | |
| | *г/ яшелчә һәм бәрәңге юу һәм савытларга тутыру бинасын* | |
| | *д/ ярдәмче бүлмәләрне:* | |
| | *- администрация-көнкүреш бүлмәләрен;* | |
| | *- хуҗалык бүлмәләрен (тара һәм инвентарь өчен складлар)* | |
| | *- автотранспортны кую һәм ремонтлау өчен лапасларны* | |
| | *е) эчке юлларны салу һәм территорияне төзекләндерү* | |
| **2.** | **Технологик җиһазларга тотыла торган чыгымнар (мең сум), шул исәптән:** | 21,100 |
| | Вентиляция системасы | |
| | Су белән тәэмин итү һәм канализация системасы | |
| | Сортларга аеру җайланмасы | |
| | Продукцияне эшкәртү җайланмасы | |
| | Савытларга тутыру җайланмасы | |
| | Суыту һәм катыру җиһазлары | |
| **3.** | **Техника сатып алу чыгымнары (мең сум), шул исәптән:** | 4,300 |
| | Технологик транспорт (Трактор МТЗ 1221+фронталь погр. + кара) 2 шәр берәмлек | |
| | Әзер продукцияне ташу өчен суыткыч рефрижераторлар | |
| | Яшелчә һәм бәрәңге җыю өчен транспорт | |
| | **Барлык чыгымнар (инфраструктураны һәм коммуникацияләрне исәпкә алмыйча ), мең сум** | 40,600 |
| *4.* | **Инфраструктура булдыру һәм коммуникация китерү чыгымнары (мең сум), шул исәптән:** | 3,400 |
| | *- килү юлларын төзү;* | |
| | *- техник шартлар булдыру;* | |
| | *- янгын -сак сигнализациясе һәм саклау максатыннан видеокүзәтү системасы* | |
| | *- электртапшыргыч линияләр, трансформатор подстанциясе һәм резерв электр бирү чыганагы* | |
| **БАРЛЫГЫ мең сум** | | 44,00 |

2017 елның 31.03. 70/2 – пр
номерлы ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-
төлек министрлыгы боерыгы белән
расланган программага
4 нче кушымта

Кош-корт үстерү, чалу һәм эшкәртү буенча эшли торган авыл хуҗалыгы эшкәртү кулланучылар кооперативларын реконструкцияләү бәясен алдан исәпләп чыгару

| № т/б | Исеме | Бәясе, мең сум |
|---|---|---|
| 1. | **Төзелеш-монтаж эшләренә, шул исәптән исәптән түбәндәгеләрне төзү өчен тотылган чыгымнар (мең сум):** | 17,100 |
| | *а/ кош-кортны чалу алдыннан асрау боксларын* | |
| | *б/ чалу цехын* | |
| | *в/ ит суыту һәм катыру камераларын* | |
| | *г/ ярдәмче бүлмәләрне* | |
| | *- администрация-көнкүреш бүлмәләре;* | |
| | *- склад бүлмәләре* | |
| | *- тире тозлау һәм аларны саклау өчен каралган бүлмәләрне* | |
| | *д/ ит эшкәртү цехларын* | |
| | *д) эчке юлларны салу һәм территорияне төзекләндерү* | |
| 2. | **Технологик җпһазларга тотыла торган чыгымнар, шул исәптән:** | 13,200 |
| | Су эчерү системасы | |
| | Тирес җыю системасы | |
| | Вентиляция системасы | |
| | Су белән тәэмин итү һәм канализация системасы | |
| | Чалу җайланмасы | |
| | Эчәк чималы субпродуктларын беренчел эшкәртү һәм тирене тозлау җайланмасы | |
| | Колбасалар һәм ярымфабрикатлар җитештерү җайланмасы | |
| | Суыту һәм катыру җиһазлары | |
| 3. | **Техника сатып алу чыгымнары, шул исәптән:** | 7,600 |
| | Технологик транспорт (Трактор МТЗ 1221+фронталь погр. + кара) | |
| | Суытылган һәм катырылган итне ташу өчен суыткычлы рефрижераторлар (3 берәмлек) | |
| | **Барлык чыгымнар (инфраструктура һәм коммуникацияләр төзүне исәпкә алмыйча , мең сум** | 37,900 |
| *4.* | **Инфраструктура булдыру һәм коммуникация китерү чыгымнары (мең сум), шул исәптән:** | 6,100 |
| | *- килү юлларын төзү;* | |
| | *- техник шартлар булдыру;* | |
| | *- янгын -сак сигнализациясе һәм саклау максатыннан видеокүзәтү системасы* | |
| | *- электртапшыргыч линияләр, трансформатор подстанциясе һәм резерв электр бирү чыганагы* | |
| | *- чистарту корылмалары;* | |

| | | |
|---|---|---|
| | *- су китерү һәм су алып китү линияләре булган суэтем башнясы* | |
| **БАРЛЫГЫ мең сум** | | 44,00 |

2017 елның 31.03. 70/2 – пр
номерлы ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы боерыгы белән расланган программага
5 нче кушымта

Бинаны колбаса цехы, ыслау цехы һәм яшелчәләрне, җиләк-җимешләрне консервалау цехы итеп реконструкцияләү бәясен алдан исәпләп чыгару

| № т/б | Исеме | Бәясе, мең. сум |
|---|---|---|
| 1. | **Төзелеш-монтаж эшләренә чыгымнар, шул исәптән түбәндәгеләрне төзү өчен тотылган чыгымнар (мең сум):** | 89,79 |
| | *а/ лабораторияләре булган кабул итү һәм сортларга аеру бинасын* | |
| | *б/ җиләкләрне саклау суыткычын* | |
| | *в/ җимешләрне саклау суыткычын* | |
| | *г/ җиләк-җимешләрне юу һәм савытларга тутыру бинасын* | |
| | *д/ ярдәмче бүлмәләрне:* | |
| | *- администрация-көнкүреш бүлмәләрен;* | |
| | *- хуҗалык бүлмәләрен (тара һәм инвентарь өчен складлар)* | |
| | *- автотранспортны кую һәм ремонтлау өчен лапасларны* | |
| | *е) эчке юлларны салу һәм территорияне төзекләндерү* | |
| 2. | **Технологик җиһазларга тотыла торган чыгымнар (мең сум), шул исәптән:** | - |
| | Вентиляция системасы | |
| | Су белән тәэмин итү һәм канализация системасы | |
| | Сортларга аеру җайланмасы | |
| | Продукцияне эшкәртү җайланмасы | |
| | Савытларга тутыру җайланмасы | |
| | Суыту һәм катыру җиһазлары | |
| 3. | **Техника сатып алу чыгымнары (мең сум), шул исәптән:** | |
| | Технологик транспорт (Трактор МТЗ 1221+фронталь погр. + кара) 2 шәр берәмлек | |
| | Әзер продукцияне ташу өчен суыткыч рефрижераторлар | |
| | Җиләк-җимеш җыю өчен транспорт | |
| | **Барлык чыгымнар (инфраструктура һәм коммуникацияләр төзүне исәпкә алмыйча ), мең сум** | |
| *4.* | **Инфраструктура булдыру һәм коммуникация китерү чыгымнары (мең сум), шул исәптән:** | |
| | *- килү юлларын төзү;* | |
| | *- техник шартлар булдыру;* | |
| | *- янгын -сак сигнализациясе һәм саклау максатыннан видеокүзәтү системасы* | |
| | *- электртапшыргыч линияләр, трансформатор подстанциясе һәм резерв электр бирү чыганагы* | |
| **БАРЛЫГЫ мең сум** | | 89,79 |

2017 елның 31.03 70/2- пр
номерлы ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы боерыгы белән расланган программага
6 нчы кушымта

## Җиләк-җимешләрне һәм кыргый җиләкләрне саклау һәм эшкәртү өчен биналар булдыру һәм аларны технологик җиһазлау бәясен алдан исәпләп чыгару

| № т/б | Исеме | Бәясе, мең сум |
|---|---|---|
| **1.** | **Төзелеш-монтаж эшләренә чыгымнар, шул исәптән түбәндәгеләрне төзү өчен тотылган чыгымнар (мең сум):** | 15,7 |
| | *а/ лабораторияләре булган кабул итү һәм сортларга аеру бинасын* | |
| | *б/ җиләкләрне саклау суыткычын* | |
| | *в/ җимешләрне саклау суыткычын* | |
| | *г/ җиләк-җимешләрне юу һәм савытларга тутыру бинасын* | |
| | *д/ ярдәмче бүлмәләрне:* | |
| | *- администрация-көнкүреш бүлмәләрен;* | |
| | *- хуҗалык бүлмәләрен (тара һәм инвентарь очен складлар)* | |
| | *- автотранспортны кую һәм ремонтлау өчен лапасларны* | |
| | *е) эчке юлларны салу һәм территорияне төзекләндерү* | |
| **2.** | **Технологик җиһазларга тотыла торган чыгымнар (мең сум), шул исәптән:** | |
| | Вентиляция системасы | 17,4 |
| | Су белән тәэмин итү һәм канализация системасы | |
| | Сортларга аеру җайланмасы | |
| | Продукцияне эшкәртү җайланмасы | |
| | Савытларга тутыру җайланмасы | |
| | Суыту һәм катыру җиһазлары | |
| **3.** | **Техника сатып алу чыгымнары (мең сум), шул исәптән:** | |
| | Технологик транспорт (Трактор МТЗ 1221+фронталь погр. + кара) 2 шәр берәмлек | 4,5 |
| | Әзер продукцияне ташу өчен суыткыч рефрижераторлар | |
| | Җиләк-җимеш җыю өчен транспорт | |
| | **Барлык чыгымнар (инфраструктураны һәм коммуникацияләрне исәпкә алмыйча ), мең сум** | 37,6 |
| **4.** | **Инфраструктура булдыру һәм коммуникация китерү чыгымнары (мең сум), шул исәптән:** | 6,4 |
| | *- килү юлларын төзү;* | |
| | *- техник шартлар булдыру;* | |
| | *- янгын -сак сигнализациясе һәм саклау максатыннан видеокүзәтү системасы* | |
| | *- электртапшыргыч линияләр, трансформатор подстанциясе һәм резерв электр бирү чыганагы* | |
| **БАРЛЫГЫ мең сум** | | 77,1 |

31.03.2017 № 70/2-пр
ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы боерыгына
2 нче кушымта

“2017 – 2020 елларга Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперациясен үстерү” ведомство максатчан программасын гамәлгә ашыру кысаларында авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативларының матди-техник базасын яхшыртуга грантлар бирү турында нигезләмә

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. “2017 – 2020 елларга Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперациясен үстерү” ведомство максатчан программасын гамәлгә ашыру кысаларында авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативларының матди-техник базасын яхшыртуга грантлар бирү турында нигезләмә (алга таба – тиешенчә Программа, Нигезләмә) Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78 статьясына, Россия Федерациясе Хокүмәтенең “Агросәнәгать комплексын үстерүнең региональ программаларының максат күрсәткечләренә ирешүгә ярдәм итү өчен Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына федераль бюджеттан субсидияләр бирү һәм бүлү турында” 2016 елның 30 декабрендәге 1556 номерлы карарына һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “2017 елга агросәнәгать комплексына дәүләт ярдәме чаралары турында” 2017 елның 10 февралендәге 77 номерлы карарына ярашлы рәвештә әзерләнде.

Әлеге Нигезләмә авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативларының матди-техник базасын яхшыртуга грантлар (алга таба – грантлар) бирү тәртибен һәм шартларын, шулай ук грантлар бирү өчен конкурс нигезендә сайлап алуны үткәрү тәртибен билгели.

1.2. Грантлар бирүнең максаты – Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперациясе системасын үстерү өчен шартлар тудыру.

1.3. Әлеге Нигезләмәдә кулланыла торган төшенчәләр:

**грант** – авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперациясен үстерү максатларында әлеге Нигезләмәнең 2.4 пунктында каралган чараларга Россия Федерациясе Хөкүмәтенең “2013 – 2020 елларга авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чималы һәм азык-төлек базарларын җайга салу дәүләт программасы турында” 2012 елның 14 июлендәге 717 номерлы карары белән расланган 2013 – 2020 елларга авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чималы һәм азык-төлек базарларын җайга салу дәүләт программасы нигезендә Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча органы территориаль бүлегендә ачылган авыл хуҗалыгы кулланучылар эшкәртү кооперативының һәм (яки) авыл хуҗалыгы сату кооперативының хосусый счетына федераль бюджеттан, Татарстан Республикасы бюджетыннан һәм (яки) җирле бюджеттан күчерелә торган акчалар;

**авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативы** – авыл хуҗалыгы кулланучылар эшкәртү кооперативы һәм (яки) авыл хуҗалыгы сату кооперативы, авыл хуҗалыгы терлеге сөтен, итен, кош-кортны, балык һәм аквакультура объектларын, бәрәңге, гөмбә, яшелчә, җиләк-җимешләрне, шул исәптән кыргый үсә торганнарын, саклау өчен әзерләп кую, саклау,хәзерләп кую, эшкәртү, сортларга аеру, сую, беренчел эшкәртү, суыту эшчәнлеген алып бара, кооперативлар әгъзалары хокукларында (ассоциациядәге әгъзалыктан тыш) кимендә 10 авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчене берләштерә, шул ук вакытта авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативы табышларының кимендә 70 проценты эшкәртү һәм (яки) сату эшчәнлеген алып бару хисабына тупланырга тиеш, яисә табышларының 70 проценты авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативлары эшчәнлегенең авыл хуҗалыгы продукциясен әзерләү, саклау, эшкәртү һәм сату кебек төрләренә охшаш эшчәнлек төрләре хисабына тупланса, кулланучылар кулланучылар җәмгыятьләре (алга таба – кооператив);

**конкурс комиссиясе** – кооперативларның матди-техник базасын яхшыртуга грантлар бирү өчен кооперативларның заявкаларын сайлап алу максатларында төзелгән ведомствоара конкурс комиссиясе;

**чыгымнар планы** – конкурс комиссиясе раславына гариза бирүче тарафыннан тапшырылган грanttан файдалануның юнәлешләре буенча чыгымнарның статьялап эшләнгән сметасы.

1.4. Грант алучы дип Татарстан Республикасында салым исәбендә торучы һәм грантлар бирүгә конкурс сайлап алуында җиңүчеләр буларак билгеләнгән кооперативлар танылa (алга таба – грант алучылар, конкурс).

## 2. Грантлар бирү күләме һәм шартлары

2.1. Грантлар кооперативларга техник-икътисадый нигезләүгә ярашлы рәвештә максатчан чыгымнарны финанслашу шартларында кире кайтарылмый торган итеп матди-техник базаны үстерүгә бирелә.

2.2. Грантлар кооперативның матди-техник базасын үстерү чыгымнары планында билгеләнгән һәр чыгым статьясының иң күбе 60 проценты күләмендә, ләкин бер кооперативка җитмеш миллион сумнан артык булмаган күләмдә бирелә.

2.3.Грантлар конкурс нәтиҗәләре буенча Грант алучыларга тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законында каралган бюджет ассигнованиеләре һәм билгеләнгән тәртиптә Министрлыкка дип расланган бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә бирелә.

2.4. Грантлар кооперативларның матди-техник базасын яхшыртуга дәүләт ярдәменең башка юнәлешләре кысаларында капланмаган чыгымнарын финанслашу өчен түбәндәгеләргә бирелә:

сөтне, авыл хуҗалыгы терлеге итен, кош-кортны, балыкны һәм аквакультура объектларын, бәрәңгене, гөмбәләрне, яшелчәләрне, җиләк-җимешләрне, шул исәптән кыргый үсә торганнарын, саклау өчен хәзерләү,

саклау, әзерләп кую, эшкәртү, сортларга аеру, чалу, беренчел эшкәртү, суыту һәм авыл хуҗалыгы продукциясен һәм аны эшкәртү продуктларын сатуга әзерләү буенча производство объектларын төзү, реконструкцияләү яки модернизацияләүгә;

сөтне, авыл хуҗалыгы терлеге итен, кош-кортны, балыкны һәм аквакультура объектларын, бәрәңгене, гөмбәләрне, яшелчәләрне, җиләк-җимешләрне, шул исәптән кыргый үсә торганнарын, саклау өчен хәзерләү, саклау, әзерләп кую, эшкәртү, сортларга аеру, чалу, беренчел эшкәртү, суыту, авыл хуҗалыгы продукциясен һәм аны эшкәртү продуктларын сатуга әзерләү, төяү, бушату, эшләп чыгарыла торган (җитештерелә торган һәм эшкәртелә торган) продукциянең сыйфатына һәм куркынычсызлыгына производство контроле һәм дәүләт ветеринария-санитария экспертизасын ясау лабораторияләрен җиһазлау (авыл хуҗалыгы продукциясенең сыйфатын анализлау өчен җиһазлар сатып алу) өчен билгеләнгән производство объектлары өчен җиһазлар һәм техника сатып алуга һәм монтажлауга. Күрсәтелгән җиһазларның һәм техниканың исемлеге Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгының “Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2016 елның 30 декабрендәге 1556 номерлы карары белән расланган Агросәнәгать комплексын үстерүнең региональ программаларының максат күрсәткечләренә ирешүгә ярдәм итү өчен Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына федераль бюджеттан субсидияләр бирү һәм бүлү кагыйдәләрендә каралган документларны раслау турында” 2017 елның 31 гыйнварындагы 45 номерлы боерыгы белән (алга таба – Россия Авыл хуҗалыгы министрлыгы) расланган.

авыл хуҗалыгы продукциясен һәм аны эшкәртү продуктларын транспортлау, ташыганда саклануын тәэмин итү һәм сату өчен махсуслаштырылган транспорт, фургоннар, прицеплар, ярымприцеплар, вагоннар, контейнерлар сатып алуга. Күрсәтелгән техника исемлеге Россия Авыл хуҗалыгы министрлыгы боерыгы белән расланган;

авыл хуҗалыгы терлеген, балыкны һәм аквакультураны саклау, әзерләп кую, эшкәртү, сортларга аеру, чалу, беренчел эшкәртү, сөтне, итне, кош-кортны, бәрәңгене, гөмбәләрне, яшелчәләрне, җиләк-җимешләрне, шул исәптән кыргый үсә торганнарын, суыту һәм авыл хуҗалыгы продукциясен һәм аны эшкәртү продуктларын сатуга, төяүгә, бушатуга һәм транспортлауга әзерләү өчен җиһазларны һәм техник чараларны лизингка алу шартнамәләре буенча кертемнәрнең бер өлешен (лизинг предметларының гомуми бәясеннән иң күбе 8 процент күләмендә) түләүгә.

2.5. Грант түбәндәге шартлар үтәлгән очракта бирелә:

а) конкурска гариза бирү датасына кооператив эшчәнлеге срогы аныц теркәлү датасыннан 12 айдан күбрәк булырга тиеш;

б) кооператив Татарстан Республикасы территориясендә законнарда билгеләнгән тәртиптә теркәлгән һәм җитештерү эшчәнлеген гамәлгә ашыра;

в) кооператив авыл хуҗалыгы кооперативларының ревизия берлеге әгъзасы булып тора һәм ел саен Министрлыкка үз эшчәнлеге нәтиҗәләре буенча ревизия бәяләмәсен тапшыра;

г) кооперативның региональ программада билгеләнгән эшчәнлек (тармак) юнәлеше буенча матди-техник базасын үстерү, җитештерелгән һәм сатыла торган авыл хуҗалыгы продукциясе күләмен арттыру планы, сарыф ителгән акчаларны иң күбе 5 ел эчендә чыгару срогы билгеләнгән чыгымнар статьяларына нигезләве бар;

д) кооператив сатып алына торган мөлкәтнең, башкарыла торган эшләрнең, күрсәтелә торган хезмәтләрнең (алга таба – Сатып алулар) исемнәрен, аларның исәбен, бәясен, финанслау чыганакларын (Грант акчалары, үз акчасы һәм (яки) кредит акчалары) күрсәтеп, чыгымнар планын тапшыра;

е) кооператив составында кимендә 10 авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүче бар;

ж) гариза бирүченең әлеге Нигезләмәгә 5 нче кушымтада каралган түбәндәгеләр турында йөкләмәсе булу:

кооператив счетына акча күчкән көннән алып 18 ай эчендә грант акчаларын куллану турында;

чыгымнар планында күрсәтелгән сатып алулар бәясенең кимендә 40 процентын, шул исәптән турыдан-туры үз акчаларыннан кимендә 10 процентын түләү турында;

грант акчаларын файдаланып сатып алынган мөлкәтне кооперативның бүленмәс фондына кертү турында;

алынган Грант акчаларының кооператив тарафыннан әлеге Нигезләмәдә каралмаган максатларда яки сроклары бозылып тотылган очракта, шулай ук кооператив таратылган яки Грант акчаларына сатып алынган мөлкәт тартып алынган (бүләк ителгән, арендага тапшырылган, алыш-биреш ясалган яки пай рәвешендәге кертем, гади кертем буларак кулланылган яисә башка төрле тартып алынган) очракта, грант акчаларын Грант бирү турындагы шартнамәнең гамәлдә булуның биш еллык срогы беткәнче кире кайтару турында;

Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгына ел саен үз эшчәнлеге йомгаклары буенча ревизия бәяләмәсен тапшыру турында;

грант алган елда кооперативта грантның һәр 3 млн. сумына кимендә бер яңа даими эш урыны, әмма кимендә бер яңа даими эш урыны булдыру турында;

яңа даими эш урыннарын грант акчаларын тотып бетергән датадан кимендә 5 ел дәвамында саклап торырга;

грант алган кооператив тарафыннан сатылган авыл хуҗалыгы продукциясе күләменең еллык артымы кимендә 10 процент булу турында;

кооператив үзе җитештергән авыл хуҗалыгы продукциясен, моңа әлеге кооператив тарафыннан бу кооператив әгъзалары җитештергән авыл хуҗалыгы чималыннан җитештерелгән беренчел эшкәртү продукциясе дә керә, җыю һәм эшкәртү, транспортлау, саклау күләмнәренә, шулай ук әлеге кооператив әгъзалары өчен башкарылган эшләргә (хезмәт күрсәтүләргә) гомуми күләмдә кимендә 50% туры килүне тәэмин итү турында;

грант акчаларын тотып бетергән датадан соң кимендә 5 ел дәвамында

финанс-хуҗалык эшчәнлеген башкару турында.

з) кооператив җитәкчесе Россия Федерациясе законнары нигезендә үзенең персональ белешмәләрен тапшыруга һәм эшкәртүгә ризалык бирә;

и) кооперативка карата үзгәртеп кору, юкка чыгару, банкротлык процедуралары үткәрелми һәм хуҗалык эшчәнлеген башкарырга чикләүләр юк;

к) кооператив әлеге Нигезләмәнең 2.4 пунктында күрсәтелгән максатларга башка норматив хокукый актлар, муниципаль хокукый актлар нигезендә Россия Федерациясе бюджет системасының тиешле бюджетыннан акча алучы булып тормый;

л) кооперативның Россия Федерациясе бюджет системасының тиешле бюджетына шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгән субсидияләрне, бюджет инветицияләрен кайтару буенча вакыты узган бурычлары һәм Россия Федерациясе бюджет системасының тиешле бюджетына кайтарылырга тиешле вакыты узган башка бурычлары юк;

м) кооперативның Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына Россия Федерациясе законнары нигезендә түләү срогы җиткән салымнар, җыемнар һәм башка түләү йөкләмәләре юк;

н) кооперативның матди-техник базасын үстерүгә элек бирелгән грант акчалары тулысынча тотылып беткән вакыттан кимендә бер ел вакыт үткәннән соң бүлеп бирелергә мөмкин.

## 3. Конкурс сайлавын үткәрү тәртибе

3.1. Конкурс сайлавында катнашу өчен гариза бирүче Министрлык билгеләгән срокта түбәндәге документларны тапшырырга тиеш:

3.1.1. Әлеге Нигезләмәгә 1 нче кушымтада каралган форма буенча кооперативның матди-техник базасын яхшыртуга грант алу өчен конкурста катнашуга заявка (алга таба – заявка);

3.1.2. Конкурс сайлавын уздыру башланган көнгә кадәр иң күбе бер ай алдан Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан алынган өземтәнең күчермәсе йә “Юридик затларның бердәм дәүләт реестры язуы бите”;

3.1.3. Кооператив уставы күчермәсе;

3.1.4. Әлеге Нигезләмәнең 2.4 пунктындагы икенче абзацында каралган максатларга грант сорап мөрәҗәгать иткәндә:

үз-үзен җайга сала торган оешмага (алга таба – СРО) проектлауга (төзүгә яки реконструкцияләүгә грант кулланылганда) рөхсәт күчермәсе беркетелгән локаль сметаларын һәм схема-сызымнарын (башкарылачак эшләр урыны фотосы, объект булган очракта – аның эчен һәм тышын төшергән фото) үз эченә алган кушымтасы булган, дәүләт экспертизасын узган проект-смета документациясе күчермәсе;

төзүгә (реконструкцияләүгә) һәм (яки) файдалануга кертүгә (төзүгә яки реконструкцияләүгә грант кулланылганда) рөхсәт кәгазе;

подрядчы оешмаларны җәлеп иткәндә яки хуҗалык ысулын кулланганда, төзелеш-монтаж эшләрен башкаруга башлангыч шартнамәләрнең күчермәләре;

3.1.5. Әлеге Нигезләмәнең 2.4 пунктындагы өченче абзацында каралган максатларга грант сөрап мөрәҗәгать иткәндә:

җиһазлар сатып алуга башлангыч шартнамәләрнең күчермәләре;

монтаж эшләрен башка чит оешмаларны җәлеп итеп башкаруга башлангыч шартнамәләрнең күчермәләре;

3.1.6. Әлеге Нигезләмәнең 2.4 пунктындагы дүртенче абзаңында каралган максатларга грант сорап мөрәҗәгать иткәндә:

Россия Авыл хуҗалыгы министрлыгы боерыгы белән раслана торган исемлек нигезендә җиһазлар һәм техника сатып алуга башлангыч шартнамәнең күчермәсе;

3.1.7. Әлеге Нигезләмәнең 2.4 пунктындагы бишенче абзацында каралган максатларга грант сорап мөрәҗәгать иткәндә:

җиһазларны һәм техниканы лизингка алу шартнамәләренең күчермәләре;

3.1.8. Бизнес-план;

3.1.9. Кооперативның бүленмәс фонды счетында гариза бирүченең үз акчаларыннан грант акчалары исәбеннән өстәмә финанслана торган чыгымнарның һәр статьясы бәясенең кимендә 40 процентын тәшкил иткән сумманың булуын раслый торган документлар.

Гариза бирүченең үз акчалары һәм (яки) кредит акчалары булуны раслый торган документлар түбәндәгеләр:

кооперативның кредит оешмасында ачылган счетыннан өземтә;

кирәкле акчаларны бирү турында кредит оешмаларында алынган кредит шартнамәләре күчермәләре;

3.1.10. Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрыннан кооперативның үзендә булган (үзендәге) күчемсез мөлкәт өбъектларына хокуклары турында өземтәләрнең вәкаләтле орган тарафыннан таныкланган һәм конкурска заявка биргән көнгә кадәр иң күбе 30 көн элек бирелгән күчермәсе (булган очракта);

3.1.11. Әлеге Нигезләмәгә 2 нче кушымтада каралган форма буенча кооперативның матди-техник базасын яхшырту чыгымнары планы проекты;

3.1.12. Әлеге Нигезләмәнең 3.1. пунктындагы “ж” пунктчасында каралган шартларны үтәү турында гариза бирүченең йөкләмәсе;

3.1.13. Әлеге Нигезләмәгә 3 нче кушымта нигезендә шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык;

3.1.14. әлеге Нигезләмәгә 4 нче кушымтада каралган форма буенча гариза бирүченең анкетасы;

3.1.15. Кооперативның урнашу урыны буенча салым органында исәпкә куелу турында таныклык күчермәсе;

3.1.16. Үз теләге белән Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына Россия Федерациясе законнары нигезендә түләү срогы җиткән салымнар, җыемнар һәм башка түләү йөкләмәләре булмау турында белешмә;

3.1.17. Авыл хуҗалыгы кооперативлары ревизия берлегеннән кооперативның аның әгъзасы булып торуы турында кооператив әгъзаларының исәбе күрсәтелгән белешмә;

3.1.18. Салым салуның гомуми (махсус) режимын куллана торган авыл хуҗалыгы куллануччылар кооперативлары өчен хисапны кабул итү турында

салым органы тамгасы салынган узган календарь елга бухгалтерия (финанс) хисабы күчермәсе йә, хисап электрон рәвештә тапшырылган очракта, аны кабул итү турында квитанция беркетелгән хисап;

3.1.19. Авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативы хезмәткәрләренең уртача айлык эш хакы турында һәм узган хисап чоры өчен исәпләнгән һәм түләнгән иминият кертемнәре буенча хисап тыпшырылу факты хакында Дәүләт учреждениесе – Россия Федерациясе Пенсия фондының Татарстан Республикасы буенча бүлеге белешмәләре;

3.1.20. Авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативы яки кулланучылар җәмгыяте вәкиле шәхесен таныклый торган документ күчермәсе;

3.1.21. Авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативы яки кулланучылар җәмгыяте вәкиле вәкаләтләрен раслый торган документ күчермәсе.

3.2. Белешмәләрнең дөреслеге һәм тапшырылган документларның чын булуы өчен җаваплылык кооператив җитәкчесенә йөкләнә. Конкурс комиссиясенә документлар әзерләү һәм тапшыру белән бәйле барлык чыгымнарны кооператив җитәкчесе түли.

Таныклау таләп ителгән һәм берничә биттән гыйбарәт документлар тапшырылганда, һәр бите таныклана. Документларның төп нөсхәләре проектны яклаганда конкурс комиссиясендәге күчермәләр белән чагыштырып карау өчен бирелә.

Әлеге Нигезләмәнең 3.1. бүлегендә күрсәтелгән документлар тегелгән, номерлар сугылган, вәкаләтле зат тарафыннан имзаланган һәм кооператив мөһере белән таныкланган булырга тиеш (булган очракта). Вәкаләтле вәкил мөһере белән расланган һәм имзасы белән таныкланган (юридик затлар өчен) яки үз кулы белән таныкланган (кооператив җитәкчесе өчен) төзәтүләрдән тыш, башка бетерүләр һәм төзәтүләр рөхсәт ителми.

Әлеге Нигезләмәнең 3.1. бүлегендә күрсәтелгән документлар конкурс сайлавын уздыру турындагы хәбәрнамәдә күрсәтелгән срокларда һәм адрес буенча тапшырыла.

Грант бирү тәртибе һәм документларның формалары турында мәгълүмат "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының http: //agro.tatarstan.ru/ рәсми сайтына: "Фермерларга, авыл хуҗалыгы кооперативларына грантлар һәм шәхси ярдәмче хуҗалыкларга субсидияләр" бүлегендә "Авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативларының матди-техник базасын яхшырту" бүлекчәсенә (алга таба – Министрлыкның рәсми сайты) урнаштырыла.

Гариза бирүче тарафыннан үз ихтыяры белән конкурс комиссиясенә (турыдан-туры әңгәмә вакытында) конкурс комиссиясенә йогынты ясый алырлык, программаның потенңиаль катнашучы буларак кооперативның уңай ягын ача торган түбәндәге документлар тапшырылырга мөмкин:

а) муниңипаль хакимият органнарынннан кооператив үсешен, аның җитештерү күрсәткечләре динамикасын, шулай ук булырга мөмкин социаль-икътисадый нәтиҗәне һәм грант бирүнең максатка ярашлы булуын күрсәтә торган тәкъдим хатлары;

б) Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрыннан авыл хуҗалыгы

кулланучылар кооперативының җир кишәрлегенә һәм (яки) күчемсез мөлкәт объектына милек хокукы турында өземтәнең күчермәсе (йә милек хокукын дәүләт теркәве турында таныклык күчермәсе) яисә заявка биргән көннән кимендә биш елга күчемсез мөлкәтне арендага алу шартнамәсе күчермәсе;

в) производство (шул исәптән салынып бетмәгән төзелеш) биналарының, авыл хуҗалыгы терлегенең, техниканың һәм җиһазларның фоторәсемнәре;

г) заявка биргән вакыттан әлеге Нигезләмәнең 3.1. пунктларында билгеләнгән таләпләргә туры китереп эшләп бетерелгән документлар;

д) массакүләм мәгълүмат чараларында чыккан мәкаләләр һәм башка документлар.

## 4. Заявкаларны кабул итү һәм теркәү

4.1. Грантлар бирү буенча конкурс сайлавында катнашуга заявкалар кабул ителә башлау турында белдерү “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Министрлыкның http: //agro.tatarstan.ru/ адресы буенча рәсми сайтына “Фермерларга, авыл хуҗалыгы кооперативларына грантлар һәм шәхси ярдәмче хуҗалыкларга субсидияләр” бүлегенә урнаштырыла.

Хәбәрнамәдә конкурс уздырылу урыны һәм вакыты (кимендә 30 календарь көн), элемтә телефоннары, Министрлык сайтының конкурс шартлары, заявка бирү тәртибе һәм турында мәгълүмат алырга, норматив документлар белән танышырга мөмкин булган бүлекләре күрсәтелә.

4.2. Заявкалар кабул ителә башлау көне дип хәбәрнамә басылып чыккан көннән соң килә торган көн санала. Хәбәрнамәдә күрсәтелгән срок узганнан соң, кооперативлардан заявкалар кабул ителми.

Алынган заявкаларны һәм документларны теркәү заявкаларны теркәү журналына язылып баруына карап башкарыла, ул номерланган, тегелгән һәм конкурс комиссиясе секретаре имзасы һәм Министрлык мөһере белән беркетелгән булырга тиеш. Заявканы теркәгәндә аңа керү номеры сугыла.

Әлеге Нигезләмәнең 3.1. бүлегендә күрсәтелгән документлар конкурс комиссиясе секретарена кәгазъдә тапшырыла. Конкурс комиссиясенә кооператив җитәкчесе тарафыннан бирелә торган барлык документларның исемнәре, номерлары һәм даталары, алардагы битләр саны ике нөсхәдә төзелә торган исемлеккә кертелә. Конкурс комиссиясе секретаре тапшырылган документларны аларга кушымта итеп бирелгән исемлек белән (әлеге Нигезләмәгә 6 нчы кушымта) чыгыштырып караганнан соң, алар кооператив җитәкчесе тарафыннан һәм мөһер белән (булган очракта) таныклана торган конвертка салыналар. Конвертта шулай ук программаның исеме, кооперативның исеме һәм кооператив җитәкчесеснең фамилиясе, исеме, атасының исеме һәм адресы күрсәтелә. Исемлек бите конвертка салынмый. Документларны кабул иткәндә исемлек битенә документларның кабул ителүен раслый торган тамга салына, кабул итү датасы һәм теркәлү номеры күрсәтелә. Кабул ителү турында тамга салынган исемлек битенең бер нөсхәсе кооператив җитәкчесендә кала, ә икенчесе документлар пакетына өстәп куела.

Заявканы һәм документларны кабул иткәндә аларның тулылыгын һәм

куелган таләпләргә туры килү-килмәвен тикшерү башкарылмый.

4.3. Министрлык конкурска документлар кабул итү тәгәлләнгәннән соң 5 эш көненнән дә соңга калмыйча документларның конкурс комиссиясенә җибәрә.

## 5. Конкурс комиссиясенең функцияләре һәм бурычлары

5.1. Конкурс комиссиясе үз эшчәнлеген законнарга, әлеге Нигезләмәгә таянып башкара һәм үз эшен авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләргә дәүләт ярдәме инфраструктурасын тәшкил итә торган оешмалар, иҗтимагый оешмалар һәм кооперативлар белән үзара хезмәттәшлектә торып оештыра.

5.2. Конкурс комиссиясенең топ бурычлары:

кооперативларның матди-техник базасын яхшыртуга грант алу өчен гариза бирүче тарафыннан тапшырылган конкурс документациясен үз вакытында, ачык һәм объектив карауны тәэмин итү;

аларның тулылыгын һәм дөреслеген, икътисадый нәтиҗәлелеген, Татарстан Республикасы икътисады өчен социаль әһәмиятле булуын һәм дәүләт ярдәме күрсәтүнең максатка ярашлы булуын билгеләү максатында проектларга экспертиза ясау;

конкурсның җиңүчеләрен һәм аларга бирелә торган грантларның күләмен билгеләү.

5.3. Конкурс комиссиясе кимендә 12 кешедән Министрлык боерыгы белән төзелә һәм конкурс комиссиясе рәисеннән, рәис урынбасарыннан, әгъзаларыннан һәм секретареннан (тавыш бирү хокукы юк) гыйбарәт була. Конкурс комиссиясенә дәүләт граждан хезмәткәрләре һәм муниципаль хезмәткәрләр, авыл хуҗалыгы өлкәсендә иҗтимагый оешмалар, берлекләр, берләшмәләр һәм мәгариф оешмалары вәкилләре кертелә. Конкурс комиссиясе әгъзалары арасында дәүләт хезмәткәрләренең һәм муниципаль хезмәткәрләрнең саны иң күбе 50 процентны тәшкил итәргә тиеш.

Конкурс нәтиҗәләрендә үз мәнфәгатьләре булган затлар (шул исәптән конкурста катнашуга гариза бирүчеләр йә күрсәтелгән гаризаларны биргән кооперативларда торучылар), йә конкурста катнашучылар йогынты ясый алган затлар комиссия әгъзалары була алмый.

Конкурс комиссиясе рәисе:

конкурс комиссиясе эшчәнлегенә җитәкчелек итә һәм аңа йөкләнгән бурычларның үтәлеше өчен җавап бирә;

конкурс комиссиясе әгъзалары арасында йөкләмәләр бүлә;

конкурс комиссиясе утырышларын алып баруны, утырышларның беркетмәләре әзерләнүне һәм конкурс комиссиясе тарафыннан кабул ителгән карарларның үтәлешен тикшереп торуны гамәлгә ашыра.

5.4. Конкурс комиссиясе рәисе урынбасары, конкурс комиссиясе утырышында рәис булмаган очракта, аның вазыйфаларын башкара.

5.5. Конкурс комиссиясе секретаре:

тапшырылган документлары белән конкурс комиссиясе утырышында каралырга тиешле заявкаларның исемлеген заявкалар кабул ителеп беткәннән

соң биш эш көне эчендә төзи;

конкурс комиссиясе утырышларының көн тәртибе буенча материаллар әзерләүне оештыра, документлар әйләнешен һәм утырышларда конкурс комиссиясе әгъзаларының катнашуын, конкурс комиссиясе утырышлары беркетмәләренең рәмиләштерелүен тәэмин итә;

5.6. Конкурс комиссиясе әгъзалары:

конвертларны ача һәм әлеге Нигезләмәдә каралган документларның булуын тикшерә;

кооперативның һәм тапшырылган документларның әлеге Нигезләмәдә куелган таләпләргә туры килүен тикшерә;

бәяләү ведомостенә кертеп, балларның исәбен саный;

гариза бирүчеләрнең чыгымнар планын килештерә һәм грант күләмен билгели;

Грантлар алучыларның гаризаларына нигезләнеп, бизнес-планнарны гамәлгә ашыру графигын аларның гамәлдә булу срогы чорына яңадан карый.

5.7. Конкурс комиссиясе заявкалар кабул итү тәгәлләнгән вакыттан соң 14 эш көненнән дә соңга калмыйча конкурс комиссиясе утырышын үткәрә, гариза бирүчеләр тарафыннан тапшырылган документларны карый, кооперативларга грантлар бирү йә бирүдән баш тарту турында карар кабул итә, ул конкурс комиссиясе утырышы беркетмәсе белән (алга таба – беркетмә) рәсмиләштерелә.

Заявкалар кабул итү төгәлләнгән көннән соң 10 эш көне эчендә, гариза бирүчеләрне турыдан-туры әңгәмәгә чакырып, конкурс комиссиясе утырышын оештыра.

Турыдан-туры әңгәмә барышында конкурс комиссиясенең һәр әгъзасы, заявкалардагы мәгълүматка һәм бирелә торган сорауларга гариза бирүченең җавапларына нигезләнеп, тиешле карар кабул итә һәм, бирелә торган грантның күләмен күрсәтеп, һәр кооператив буенча тавыш бирү кәгазенә язма кертә.

5.8. Конкурс комиссиясе карары, конкурс комиссиясе составының яртысыннан күбрәге булганда, тавышларның күпчелегенә таянып кабул ителә. Тавышлар тигез булганда, конкурс комиссиясе утырышында рәислек итүченең тавышы хәлиткеч була. Конкурс комиссиясе секретаре тавыш бирергә хокуксыз.

Билгеләнгән критерийлар буенча баллар санын бертигез җыйган берничә дәгъва итүче булып, катнашучыларның сан составы буенча тиешле грант саны булмаганда, грант “Конкурска заявкалар теркәүнең 1 номерлы журналы”нда алданрак теркәлгән гариза иясенә бирелә.

Тавыш бирү кәгазъләрендә конкурс комиссиясе әгъзалары тарафыннан күрсәтелгән карарларга нигезләнеп, секретарь конкурс бюллетенен төзи. Тавыш бирү кәгазъләре һәм конкурс бюллетене беркетмәгә өстәп куела.

5.9. Конкурс комиссиясе утырышлары аларны уздыруга ихтыяҗ булган саен үткәрелә. Конкурс комиссиясе әгъзалары утырышка рәис карары буенча чакырыла.

Конкурс комиссиясе утырышлары, аларда әгъзаларының кимендә яртысы катнашкан очракта, тулы хокуклы була.

5.10. Конкурс комиссиясе, гариза бирүчеләр тарафыннан тапшырылган документларга ясалган анализга нигезләнеп, түбәндәге критерийларга карап, конкурс сайлавы җиңүчеләрен билгели:

| № т/б | Критерий исеме | Күрсәткечләр | Баллар белән бәяләү |
|---|---|---|---|
| 1 | Конкурс сайлавында катнашу очен заявка бирү вакытына гариза бирүче милкендә һәм (яки) кимендә 5 еллык срокка озак вакытлы арендада авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерү һәм эшкәртү өчен билгеләнгән производство биналарының булу-булмавы | юк | 0 |
| | | 300 кв. м кадәр | 5 |
| | | 300 кв.м дан күбрәк | 10 |
| 2 | Һәр 3 млн. сумга эш урыннары булдыру | 2 | 5 |
| | | 3 һәм аннан күбрәк | 10 |
| 3 | Бизнес-планда каралганча үз бәясен чыгару срогы | 5 елдан күбрәк | 0 |
| | | 3 елдан алып 5 елга кадәр | 5 |
| | | 3 ел булганчы | 10 |
| 4 | Матди-техник базаны яхшырту өчен чыгымнар планына карата үз акчалары суммасы | 41 – 45% | 5 |
| | | 45 % күбрәк | 10 |
| 5 | Кооператив әгъзалары исәбе | 11-15 әгъза | 5 |
| | | 15 әгъзадан күбрәк | 10 |
| 6 | Кооператив җитәкчесенең эшлеклелек сыйфатларын, һөнәри осталыгын, социаль һәм бюджет җаваплылыгын бәяләү (срокларын, мәҗбүри түләүләр күләмнәрен һәм хезмәт хакы түләү срокларын үтәү) | Максималь балл – 20 | |

5.11. Баллар бары тик тегелгән документлар буенча санала, конкурс комиссиясе утырышында тапшырылган документлар балл суммасына кушылмый. Җыярга момкин булган балларның иң күбе 60 була. Конкурс комиссиясе уңай карар чыгарсын өчен 20 балл җыярга кирәк. Конкурс сайлавының җиңүчеләре булып, барысын да кушканнан соң, иң күп балл җыйган гариза бирүчеләр танылa.

5.12. Беркетмә конкурс комиссиясе рәисе һәм аның урынбасары, секретаре һәм утырышта катнашкан конкурс комиссиясе әгъзалары тарафыннан имзалана. Министрлык беркетмә имзаланганнан соң 5 көн эчендә конкурс сайлавы нәтиҗәләрен раслау турында боерык чыгара һәм конкурста катнашучыларга хәбәр итү өчен Министрлыкның муниципаль районнардагы

Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәләренә конкурс комиссиясенең кабул ителгән карары турында хәбәр иткән хат юллый.

Конкурс йомгаклары турында мәгълүмат, җиңүчеләр турында Министрлык боерыгы расланган көннән алып 3 эш көненнән дә соңга калмыйча, Министрлыкның рәсми сайтына урнаштырыла.

5.13. Конкурс комиссиясе, объектив сәбәпләр аркасында чыгымнар планы нигезендә грант акчаларын тотуга каршылык тудыра торган эшкуарлык эшчәнлеге шартлары үзгәргән йә гариза бирүче проектны гамәлгә ашырудан баш тарткан очракта, күрсәтелгән үзгәрешләрне килештерү һәм өстәмә утырыш уздыру турында карар кабул итә.

Конкурс төгәлләнгәннән соң 30 эш коне эчендә барлык заявкаларны һәм документларны, шулай ук конкурс комиссиясе тарафыннан кабул ителгән барлык документларны грант акчаларын тотып бетергәннән соң биш ел дәвамында саклау өчен Министрлык архивына тапшыра.

5.14. Әгәр конкурска бирелгән заявкаларның саны яки грант откан кооперативларның саны финанслау бүленгән кооперативлар саныннан кимрәк булса, Министрлык әлеге нигезләмәдә каралган тәртип буенча уздырыла торган яңа конкурс игълан итә.

## 6. Грант бирү һәм аны кире кайтару тәртибе

6.1. Министрлык Татарстан Республикасы бюджет акчаларын төп бүлүче булып тора һәм акчаларны эш көннәрендә исәпләнә торган биш көнлек срокта Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсендә ачылган хосусый счетыннан Идарәләрнең Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсенең территориаль бүлекләрендә ачылган хосусый счетларына күчерә.

Акчаларны Идарәгә күчерү өчен нигез итеп Татарстан Республикасы муниципаль районына бирелергә тиешле грантлар турындагы җыелма исәп-хисап белешмәлеге алына, анда Министрлык боерыгы белән расланган форма буенча грант алучылар һәм шартнамәләр күрсәтелә.

6.2. Министрлык грант алу өчен тапшырылган документларны, аларның керүенә карап, махсус журналда терки, ул номерланган, тегелгән, Министрлык мөһере белән расланган булырга тиеш. Теркәү язмасында теркәү номеры, документларны кабул итү коне һәм конкурс комиссиясе нәтиҗәләре буенча грант суммасы күрсәтелергә тиеш.

